Добавил(а) Administrator
жомга, Май 25, 2012 12:00

**Отчет начальной профсоюзной организации МБОУ "Евлаштауская СОШ Сабинского муниципального района" на 2012-2013 годы.**

**Саба районы Явлаштау урта мәктәбе башлангыч профсоюз комитетынын 2012-2013 нче елларга отчеты.**

Явлаштау урта мәктәбенен башлангыч профсоюз оешмасында Явлаштау урта мәктәбеннән 24 укытучы һәм 6 ярдәмче хезмәткәр, Мишәбаш башлангыч мәктәбеннән 5 укытучы һәм 1 ярдәмче хезмәткәр, Явлаштау "Ромашка" балалар бакчасыннан 7, Мишәбаш "Тюльпан" балалар бакчасыннан 8 хезмәткәр, барысы- 51 хезмәткәр әгъза булып торалар. Шулай ук безнен мәктәплләрдән эшләп ялга чыккан 13, балалар бакчасыннан 4, барысы- 17 пенсионерыбыз бар. Безнен оешма профсоюз уставы белән башлангыч профсоюз оешмасы турында тозелгән положение, еллык план нигезендә эш алып бара. Профсоюз оешмасы һәм админстрация арасында тозелгән килешvдәге барлык пунктларнын vтәлv vтәлмәве профком утырышларында яисә директор алды кинәшмәләрендә тикшерелә. Без – профсоюз оешмасы мәктәп дирекциясе белән килешеп, анлашып эшлибез. Безнен оешманын топ бурычы булып тvбәндәгеләр тора:
- Профсоюз členнарынын мәнфәгатьләрен, администрация каршында хезмәткәрләрнен социаль- экономик хокукларын яклау;
- Профсоюз членнарына социаль һәм хокукый яклау буенча кинәшләр бирv;
- Профсоюз членнарынын буш вакытларын файдалы итеп vткәрергә булышу.

Конституциядә каралганча, барлык сау-сәламәт кеше хезмәткә хокуклы. Тырышып хезмәт итv һәм хезмәт дициплинасын vтәv һәркемнен топ бурычы булып тора. Хезмәт дисциплинасы ул- эчке тәртип кагыйдәләрен vтәv генә тvгел, ә vз профессиясенә анлы рәвештә ижади якын килеп, югары нәтижәләргә ирешv, эш вакытын дорес итеп файдалану. Эчке тәртип кагыйдәләре хезмәткә анлы караш булдыруны, хезмәт дисциплинасын ныгытуны, эш сәгатен дорес файдалануны, югары нәтижәлелеккә ирешvне максат итеп алу. Хезмәткәрләрне эшкә алу хезмәткәрнен шәхси гаризасы һәм приказ нигезендә башкарыла , тиешле документлар туплана. Хезмәт килешvе тозелә. Эшкә килгән һәрбер хезмәткәр мәктәп уставы, эчке тәртип кагыйдәләре, эш шартлары, хезмәт хакы, хокук һәм бурычлары белән таныштырыла. Мәктәпләрдә һәм балалар

бакчаларында 6 конлек эш атнасы. Педагогик хезмәткәрләрнен эш вакыты дәресләр расписаниесе һәм топ вазыйфаларыннан чыгып билгеләнә. Укытучылар 18 сәгатьтән ким булмаган нагрузка белән тәэмин ителгәннәр. Хезмәт кvрсәтvче эшчеләрнен эш вакыты хезмәт кодексы нигезендә атнасына 36 сәгать тәшкил итә. Бәйрәм алларыннан эш коннәре 1 сәгатькә кыскартыла. Педагогик хезмәткәрләр Положение нигезендә 5 елга бер тапкыр аттестацияләнәләр, елга бер тапкыр медицина тикшерvе vтәләр. Хезмәткәрләр конгә 2 тапкыр кайнар аш белән тәэмин ителгәннәр.
Мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында эшләvче хезмәткәрләрнен 16 яше тулмаган балалары булган хатын-кызларга айга 1 кон, инвалид баласы булганнарга 4кон буш тvләvле ял бирелеп килә. Бу нигездә якындагы каникул вакытында башкарыла.
Уку елы дәверендә 4-5 хезмәткәргә матди ярдәм кvрсәтәбез. Коллективыбыз бик дус, тату. Шатлыкларны бvлешеп, кайгыларны уртаклашып яшибез.
Шулай ук тvләvле яллар хезмәткәр vзе ойләнгән яки киявгә чыккан очракта 3 кон, баласы туена 1кон, яна йортка кvчкәндә 2 кон, якыны vлгән очракта 3 кон, улын армиягә озатучыга 2 кон, баласын беренче тапкыр 1 сыйныфка озатучыга һәм 11 сыйныфта сонгы звонок бәйрәмнәренә бару очен 1 кон, ир кешенен баласы туган очракта 2 кон, ойдә 80 яшьтән арткан олкән кешесе булганнарга кварталга бер кон тvләvле яллар бирелеп килә. Эш белән беррәттән vзебезнен ялыбызны да кvнелле итеп оештырабыз. Ел саен Казан шәһәренә экскурсияләргә барабыз. Үткән ел Биләр шәһәрчегенә экскурсия оештырдык. 8 укытучыбыз район профсоюз комитеты оештырган Санкт-Петербург шәһәренә экскурсиядә катнашты. Укытучылар коне, Яна ел, 8 март, 23 февраль бәйрәмнәрен матур итеп оештырабыз. Профсоюз членнарынын балалары белән берлектә vткәрелә торган чыршы бәйрәмнәре аеруча vзенчәлекле була. Культуралы ял итvдә ветераннарыбызны да онытмыйбыз. Белем бәйрәме, Олкәннәр коне, Укытучылар коне, Яна ел, 8 март, Сонгы кынгырау бәйрәмнәренә чакырабыз. Истәлекле бvләкләр тапшырабыз, чәй табыны әзерлибез, яна елга кvчтәнәчләр жибәрәбез, тvгәрәк даталары булганда туган коннәре белән тәбрикләvләр оештырабыз.
Укыту-тәрбия процессында катнашучы һәркем
-учрежденияянен Уставын,эчке тәртип кагыйдәләрен vтәргә;
-эш сәгатьләрен житештерvчән хезмәт очен дорес файдаланырга;
- янгын куркынычсызлыгын,хезмәт куркынычсызлыгы кагыйдәләрен vтәргә тиеш икәнлеген белеп эш йортә.
Каникул вакыты эш коне булып тора. Санатор-курорт дәвалану чорына отпуск графиктан тыш билгеләнә. Быел ике укытучыбыз "Сосновый бор" санаториясендә сәламәтлекләрен ныгытып кайттылар. Татар телендә ясалган, мәгариф һәм мәдәният олкәсе белән бәйле интернет-ресурсларны барлау, аларны популярлаштыру, әлеге интернет-ресурс авторларына ярдәм кvрсәтv максатыннан, жаваплылыгы чикләнгән "Белем.ру" жәмгыяте инициативасы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татнетны vстерv фонды һәм кvп санлы иганәчеләр ярдәме белән оештырылучы "Белем жәvһәрләре" Ботендонья интернет-проектлар бәйгесендә Явлаштау урта мәктәбенен http://marsila.org.ru/ сайты "Белем жәvһәре" дигән дәрәжәле исемгә лаек булды. Без "Урта белем учреждениесе - жәvһәрләр чыганагы" номинациясендә жинv яуладык. "Белем жәvһәрләре-2013" ботендонья интернет-проектлар бәйгесе жинvчеләрен бvләкләv 14нче октябрь конне Галиәсгар Камал театры бинасында vтте. Әлеге сайттан мәктәпнен профсоюз эшчәнлеге белән тулысынча танышып барырга момкин.

"Кызыксындырып укыткан кеше генә белем бирә" дигән канатлы сvзләрне безнен укытучылар исләреннән чыгармыйлар. Һәрбер укытучы һәр дәресе файдалы булсын очен кондәлек матбугаттан, остәмә чыганаклардан, тарихи истәлекләрдән оста файдаланалар. Момкинлекләре булганда тәжрибәләрен район укытучылары белән дә уртаклашалар. Бердәм Дәvләт имтиханнары биргәндә кочләреннән килгәнчә, вакытларын кызганмыйча укучылар белән даими шогыльләнәләр. Шуна да укучыларыбыз әлеге имтиханнарны унышлы гына бирәләр. Ә район олимпиадалары жинvчеләре әзерләгән укытучылар Усманова Ш.Г., Габдрахманов Р.Ш., Ярмиева Г.М., Фазыйханова А.И. ларга профсоюз елкасы бәйрәмендә рәхмәт хатлары тапшырылды.
Мәктәп яны тәжрибә участогы житәкчесе Фәйзрахманова Нуркыя Мохәммәтхановнанын эшен аерым әйтеп vтми момкин тvгел. Һәр елны бакчадан яхшы гына уныш алына һәм балаларда хезмәткә мәхәббәт, табигатькә сакчыл караш тәрбияләнә.
Берничә ел рәттән шигабиева Фәйрvзә Нурисламовна житәкчелегендә укучыларнын жәйге ялы матур гына оештырылып килә. Безнен профсоюз членнарынын балалары бу исемлеккә ин беренче кертелә. Быел мәктәп яны лагерында 8, район лагерында 10, санаторийларда 3 бала ял итте.
Ашханәдә укытучылар да, укучылар да кайнар аш белән тәэмин ителгән. Пешекчеләребез эшләрен намус белән башкаралар.
Мәктәп чиста, похтә, жылы булсын очен ярдәмче хезмәткәрләребез дә тырышып кына эшлиләр. Мәктәпнен чисталыгы укучылар сәламәтлеге очен гаять әһәмиятле икәнлеген алар тирәнтен анлыйлар. Коллективта хезмәткәрләрнен уртача яше 38 яшь.
Коллективта бер-беренә ярдәм итv, кайгы яки шатлык бvлешv, хезмәттәшеннен хәленә керv кебек унай сыйфатлар эшкә дәрт, кvнелгә рәхәтлек бирә.
Мәктәпкә бу уку елында косметик ремонт vткәрелде. Укытучылар һәм ярдәмче хезмәткәрләр бар тырышлыклырын куеп ремонт эшен башкардылар. Аларга тырышлыклары очен администрация тарафыннан рәхмәт житкерелде.
Мәктәп коллективы алдында торган бурычларнын унышлы vтәлеше балалар бакчасыннан ук башлана. Явлаштау һәм Мишәбаш балалар бакчаларында эшләvче һәр тәрбияче, хезмәткәр vз эшләрен намус белән башкаралар. Газизова Әлфир һәм Газизова Нурфияләр житәклəгән балалар бакчаларында vткәрелгән чаралар кvпкырлы. Биредә эшләгән һәр тәрбияче балаларны яратып, vз итеп, vзләренә тапшырылган эшне намус белән башкаралар. Гомумән бу коллективларнын эшләре нәтижәле, матур булуы, балалар бакчаларынын капкаларын ачу белән vк кvренә. Бакча биналарына косметик ремонтлар vткәрелде. Жәй буе бакчаларында чәчәкләр, яшелчәләр vстерелде.

Коллективлар дус, тату. Алга куелган максатларга ирешvдә монын әһәмияте зур. Балаларга тиешле тәрбия һәм белем бирvдә, сәламәтлекләрен саклау һәм ныгытуда барлык чаралар нәтижәле файдаланыла. Бакчаларда монын очен барлык шартлар да тудырылган.

Гомумән, профсоюз оешмасындагы һәр кеше vзенә бирелгән, йокләнгән эшнен асылын анлап, vз остендә жаваплылык тоеп эшләргә тырыша.

Сvземне йомгаклап, мин ике еллык профсоюз эшчәнлеген канәгатьләнерлек дип бәяләргә тәкъдим итәм. Һәммәгезгә дә саулык-сәламәтлек, гаилә бәхете, кvнел тынычлыгы телим. Эшегездән тәм, тормышыгыздан ямь табып яшәргә язсын! Игътибарыгызга зур рәхмәт.